АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«21» июня 2019** № 24

Казан

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 46 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 18 ноябрь, 906-нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, идарә каршындагы Иҗтимагый совет турында типлаштырылган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү белән бәйле,

БОЕРУ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 46 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Иҗтимагый совет составы һәм саны Министрлык, Дәүләт комитеты, идарә каршындагы Иҗтимагый советның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртибе нигезендә башкарма орган боерыгы белән раслана.»;

2.1 пунктының дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пункт түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә түземсезлекне формалаштыру.»;

3-нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Иҗтимагый совет составы Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы идарәсе каршындагы Иҗтимагый советның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртибе нигезендә төзелә.

Иҗтимагый совет агентлык тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә аның составында 17 кеше ирекле катнашу нигезендә төзелә.

3.2. Агентлык Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый совет рәисе һәм рәисе урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе агентлык җитәкчесе мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил итә торган күләмдә карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый Советның җаваплы секретарен билгели.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы Иҗтимагый советның яңа формалашкан составының беренче утырышын үткәрү көненнән өч ел тәшкил итә.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Агентлык боерыгы нигезендә Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча түбәндәге очракларда туктатыла:

аңа Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләү;

административ арест рәвешендә аңа административ җәза билгеләү;

дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайлау вазыйфасына кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәү, шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре срогы чыгу;

аның Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирү;

аның сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашу мөмкинлеге булмау;

аңа карата чыгарылган суд карары үз көченә керү;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны эшкә яраксыз яисә билгесез дип тану;

утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча аларның этик нормаларын бозу;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә системалы сәбәпсез (өч тапкырдан артык) катнашмау;

даими (ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарының күрсәтмәләренең нигезле сәбәп булмаганда үтәлмәү;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү;

аның чит ил дәүләтләренең гражданлыгын алу;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Агентлык боерыгы нигезендә, Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарын тәкъдим итү нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган хәлләрне ачыклау очрагында гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы-уникенче абзацларында каралган шартлар барлыкка килү турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.»;

5.4 пунктының өченче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Иҗтимагый совет утырышында тавышлар тигез булганда рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.»;

5.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен чакырылган булырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.12.1 пункт өстәргә:

«5.12.1. Иҗтимагый совет аның эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуын тәэмин итә.».

5.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.14. Агентлык Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра.»

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче Т.И. Минуллина